СОВЕТ НОРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«31» октябрь 2024 ел № 115

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 декабрендәге 119 номерлы “Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башлыгы, Норма авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү тәртибе турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының 2024 елның 23 октябрендәге 288 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы “Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына Контроль-хисап палатасы рәисенә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен акчалата бүләкләү турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Норма авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 декабрендәге 119 номерлы “Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башлыгы, Норма авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү тәртибе турында”гы (25.05.2023 № 80, 23.07.2024 № 108 үзгәрешләр белән) карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 2 пунктчасында «13323» санын «13990» санына алмаштырырга;

1.2. Норма авыл җирлеге башлыгының, Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы Тәртибенең 1 пунктында «19991» санын «20991» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет-ресурсында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗанов